РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.02.2018 № 3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шәмәрдән авыл җирлеге Советы тарафыннан
2006 нчы елның 28 нче декабрендә кабул ителгән
61 нче номерлы « Шәмәрдән авыл җирлегендә халык
алдында тыңлаулар турында нигезләмәне раслау хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 нче елның 31 гыйнварыннан 02-08-02-19-2018 номерлы Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2006 нчы елның 28 нче декабрендә кабул ителгән 61 нче номерлы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы карары белән расланган Шәмәрдән авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар турында нигезләмәнең 3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Халык алдында тыңлауларга:

- муниципаль берәмлекнең устав проекты, шулай ук әлеге уставны Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль законнар, Конституция (Устав) законнары яки Россия Федерациясе субъекты законнарына туры китерү максатыннан төгәл

күчереп язу формасыннан тыш уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кертү проекты;

- җирле бюджет проекты һәм аның үтәлешетурында хисап;
- муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;
- гамәлдәге законнар нигезендә тавыш бирү тәртибендә яки җыенда халыктан рөхсәт алу таләп итә торган сораулардан тыш, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору сораулары чыгарыла.

Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияне төзекләндерү проектлары, әлеге расланган документларга үзгәреш кертү проектлары, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән куллану төрен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә үзгәртү карары проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары чикләреннән тайпылышка рөхсәт бирү карары проектлары, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерү, расланган җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре булмаган очракта җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының бер рөхсәт ителгән куллану төреннән икенче рөхсәт ителгән куллану төренә үзгәртү буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар һәм аерым муниципаль норматив-хокукый актлар исәпкә алып, халык алдында тыңлаулар үткәрелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында«Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча һәм авыл җирлегенең информацион стендларында бастырырга.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев